**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә**

Рәсмиләштерү датасы - 2025 елның 20 феврале

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2018 елның 14 декабрендәге 28/2 номерлы Столбище авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында үткәрелде.

Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру проекты каралды.

Гавами тыңлауларда катнашучылар саны 10 кеше тәшкил итте.

Әлеге бәяләмә 2025гелның 19 февралендәге 1 номерлы гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә әзерләнгән.

Гавами тыңлаулар уздыру чоры дәвамында аларда катнашучылардан тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кермәде.

Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча нәтиҗәләр:

1. Гавами тыңлаулар узган дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге, Усад авылы территориясен планлаштыру проектын, 2025 елның 19 февралендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен, шулай ук әлеге бәяләмәне йомгаклау раслау өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

Гавами тыңлаулар рәисе __________________________Әбдрәфиев А.А.

Гавами тыңлаулар секретаре __________________________ Гәрәева Э.В.